РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
Глава
Сапеевского сельского поселения
Азнакаевского
муниципального района

ул. Школьная, д. 53В, Азнакаевский район,
с.Сапеево, 423326.
тел./факс (885592)44-2-40
E-mail: Sap.Azn@tatar.ru

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
Азнакай муниципаль районы
Сәпәй авыл җирлеге
башлыгы

Мәктәп ур., 53В йорт, Азнакай районы, Сәпәй
авылы, 423326
тел./факс (885592)44-2-40
E-mail: Sap.Azn@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**29.04.2022г.** **№ 2**

Азнакай муниципаль районы «Сәпәй авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында проект буенча ачык тыңлаулар билгеләү хакында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 31нче маддәсе, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 28 статьясы, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль берәмлеге «Сәпәй авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге уставы, Азнакай муниципаль районы авыл җирлегендә гавами тыңлауларны оештыру һәм уздыру тәртибе турындагы нигезләмә нигезендә, карар итәм:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы авыл Сәпәй җирлеге Советының 2014-елның 24 гыйнварендәге 78номерлы карары белән расланган, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы «Сәпәй авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында проект буенча ачык тыңлаулар билгеләргә (05.05.2016 №30-1, 24.11.2016 №40, 04.09.2017 №60, 02.07.2018 №98, 14.03.2019 №124, 19.02.2020 №155, 11.08.2021 №33 карарлар редакциясендә)

2. Билгеләргә:

- Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы авыл җирлегенең җирдән файдалану һәм төзелешләр кагыйдәләре проектын әзерләү буенча ачык тыңлауларны оештыручы комиссияне;

- үткәрү вакыты - 2022 елның 04 маеннан 2022 елның 01 июненә кадәр 17.00 сәгатьтән 18.00 сәгатькә кадәр;

- үткәрү урыны – Сәпәй авылы, Казан урамы, 19 йорт;

- тикшерелә торган мәсьәлә буенча язма тәкъдимнәр һәм искәрмәләр кертелергә мөмкин булган адрес - Сәпәй авылы, Мәктәп урамы, 53В йорты,Азнакай муниципаль районы Сәпәй авыл җирлеге башкарма комитеты.

4. Азнакай муниципаль районы авыл җирлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проектын әзерләү комиссиясенә тәкъдим итәргә:

- Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы «Сәпәй авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турындагы проект буенча гамәлдәге законнар нигезендә һәм әлеге карар белән билгеләнгән срокларда ачык тыңлаулар әзерләргә һәм уздырырга.

ачык тыңлаулар үткәрү нәтиҗәләре турында бәяләмә әзерләргә һәм билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгарырга;

- Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы «Сәпәй авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән куллану кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында проектын Интернет мәгълүмат-/телекоммуникаця челтәрендә Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга: http://aznakaevo.tatar.ru/.

5. Әлеге карарны «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталы»нда түбәндәге веб-адрес буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә: http://pravo.tatarstan.ru һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга: http//aznakayevo.tatar.ru/.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Башлык Ф.Г.Галиева